РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРТАШСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422069, Республика Татарстан, Сабинский район,
д.Два поля Арташ, ул. Тукая, 61
тел. (84362) 44-7-15

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ АРТАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

422069, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Ике басу Арташ авылы, Тукай урамы, 61 йорт
тел. (84362) 44-7-15

e-mail: Art.sab@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
21.02.2022

КАРАР
№5

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру кысаларында файдаланыла торган тикшерү кәгазе формасын (контроль сораулар исемлеге) раслау турында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында '' 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 53 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру кысаларында файдаланыла торган тикшерү кәгазе (контроль мәсьәләләр исемлеге) формасын расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча, Саба муниципаль районының Арташ авыл җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/rus/michan адресы буенча бастырып чыгарырга һәм җирлекнең мәгълүмати стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә калдырам.

Арташ авыл
җирлеге башлыгы

А. Р.Әгъләмҗанов

РАСЛАНГАН
Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге Башкарма комитетының 2022 елның 21 февралендәге 5 номерлы карары белән

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру кысаларында файдаланыла торган тикшерү кәгазе (контроль сораулар исемлеге) формасы

Тикшерү кәгазенең (контроль сораулар исемлеге) әлеге формасы (алга таба - тикшерү кәгазе) Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Арташ авыл җирлеге территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру кысаларында үткәрелә торган планлы тикшерүләр барышында кулланыла.

Планлы тикшерү предметы әлеге тикшерү кәгазенә кертелгән мәҗбүри таләпләрне үтәү белән чикләнә.

1. Муниципаль контроль органы исеме:______________________________________
_______________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________.

2. Шәхси эшмәкәрнең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булса), ИНН, ОГРН/ОГРНИП, аңа карата тикшерү үткәрү:_______________________________________
_______________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________.

3. План буенча тикшерү үткәрү урыны_____________________________________
_______________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________________.

4. Тикшерү үткәрү турында күрсәтмә реквизитлары ______________________
_______________________________________________________________________________.

5. Тикшерүнең хисап номеры һәм тикшерүләрнең бердәм реестрында тикшерү хисап номерын бирү датасы _____________________________________________.

6. Планлы тикшерү уздыручы һәм тикшерү кәгазе тутыручы вазыйфаи затның вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме ______________________________
_______________________________________________________________________________
_______________________________________________________________________.

7. Юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан тикшерү предметы булган мәҗбүри таләпләрнең үтәлүен яки үтәлмәвен раслый торган мәҗбүри таләпләрнең эчтәлеген чагылдыручы мәсьәләләр исемлеге:

| № п/п | Мәҗбүри таләпләрнең эчтәлеген чагылдыручы мәсьәләләр | Мәҗбүри таләпләр билгеләнгән структур берәмлекләрен күрсәтеп, норматив хокукый актлар | Сорауларга җаваплар | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Әйе | Юк | Килешмәү | Искәрмә |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | реквизитлары | | | | |
| 1 | Юридик зат яки шәхси эшмәкәр тарафыннан тикшерелә торган җир кишәрлеге максатчан билгеләнеше һәм (яки) рөхсәт ителгән куллану төре нигезендә файдаланыламы? | Россия Федерациясе Җир кодексының 7 статьясындагы 2 пункты, 42 статьясы | | | | |
| 2 | Тикшерелүче юридик затның яки шәхси эшмәкәрнең Россия Федерациясе законнарында каралган җир кишәрлегенә файдаланыла торган җир кишәрлекләренә, (кулланыла торган җир кишәрлекләренә, җир кишәрлекләренең бер өлешенә) хокукы бармы? | Россия Федерациясе Җир кодексының 25 статьясындагы 1 пункты | | | | |
| 3 | «Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында»2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән тәртиптә файдаланыла торган җир кишәрлекләренә (кулланыла торган җир кишәрлекләренә, җир кишәрлекләренең бер өлешенә) хокуклар яисә йөкләмәләр теркәлдеме? | Россия Федерациясе Җир кодексының 26 статьясындагы 1 пункты, Россия Федерациясе Граждан кодексының 8.1 статьясы | | | | |
| 4 | Хокук билгели торган документларда күрсәтелгән җир кишәрлеге мәйданының юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан кулланыла торган мәйданы туры киләме? | Россия Федерациясе Җир кодексының 25 статьясындагы 1 пункты, 26 статьясындагы 1 пункты | | | | |
| 5 | Юридик зат, шәхси эшмәкәр кулланыла торган җир кишәрлеге чикләренең борылыш нокталарының нигезләмәсе Күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрында күрсәтелгән җир кишәрлеге чикләренең нигезләмәләре турындагы белешмәләргә туры киләме? | Россия Федерациясе Җир кодексының 6 статьясындагы 3 пункты, 25 статьясындагы 1 пункты | | | | |
| 6 | Дәүләт яки муниципаль милектә булган җир | Россия Федерациясе | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | кишәрлегеннән (җир кишәрлекләреннән) файдалану мондый җирләр яки җир кишәрлекләре чикләрендә туфракның уңдырышлы катламын бозуга яки юк итүгә китергән очракта, җир яки җир кишәрлекләре рөхсәт ителгәнчә файдалану өчен яраклы халәткә китерелгәнме? | Җир кодексының 13 статьясындагы 5 пункты, 39.35 статьясындагы 1 пунктчасы | | | | |
| 7 | Сервитутның гамәле туктатылган очракта, тикшерелә торган юридик зат, шәхси эшмәкәр тарафыннан сервитут билгеләнгән очракта, җир кишәрлеген куллану өчен яраклы халәткә китерү бурычы рөхсәт ителгән куллану нигезендә башкарыламы? | Россия Федерациясе Җир кодексының 13 статьясындагы 5 пункты, 39.25 статьясындагы 9 пунктчасы | | | | |
| 8 | Тикшерелүче юридик зат (дәүләт хакимияте органы, җирле үзидарә органы, дәүләт һәм муниципаль (бюджет, казна, автоном), казна предприятиесе, Россия Федерациясе Президентының үз вәкаләтләрен үтәүне туктаткан тарихи мирас үзәгеннән тыш) җир кишәрлегеннән (җир кишәрлекләреннән) даими (сроксыз) файдалану хокукын яңадан рәсмиләштерү яисә җир кишәрлеген (җир кишәрлекләрен) милеккә алу хокукын яңадан рәсмиләштерү бурычы үтәлдеме? | «Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында»2001 елның 25 октябрендәге 137-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 2 пункты | | | | |
| 9 | Җир кишәрлеген законнарда билгеләнгән срокларда файдалану (үзләштерү) мәҗбүрилеге турында таләп үтәләме? | Россия Федерациясе Җир кодексының 42 статьясы, | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Россия Федерациясе Граждан кодексының 284 статьясы, «Гражданнарның коммерциягә карамаган бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача берләшмәләре турында»1998 елның 15 апрелендәге 66-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясындагы 2 өлешенең 7 пункты, Россия Федерациясе Җир кодексының 45 статьясындагы 2 пункты | | | | |

«___» ______________ 20___ ел.
(тикшерү кәгазен тутыру датасы күрсәтелә)

______________________________ ______________ __________________________
(тикшерү кәгазе тутырган зат вазыйфасы) (имза) (Тикшерү кәгазе тутырган зат фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда)